ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**20.03.2023 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№705**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 октябрендәге 2686 номерлы карары белән расланган, мәгълүмати элмә такталар урнаштыру, элмә такталар урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Административ регламентларны актуальләштерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 октябрендәге 2686 номерлы карары белән расланган, мәгълүмати элмә такталар урнаштыру, элмә такталар урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 3.3.2.1 пунктындагы унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында һәр юлын тутыру процессында формалаштырылган рәсми мөрәҗәгатьне формаль-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, Бердәм порталда автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында дөрес тутырылмаган юллары ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша җиткерелә».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында ((http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырылуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин